ГЛАВА
МАЛЬБАГУШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Нефтяников, д30, с.Мальбагуш,
Азнакаевский муниципальный район 423330

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ МӘЛБАГЫШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Нефтьчеләр ур., 30 нче йорт, Мәлбагыш
авылы, Азнакай муниципаль районы, 423330

Тел./факс(885592)3-77-90,3-77-91; E-mail:Malb.Azn@tatar.ru,

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«13» ноябрь 2024 ел № 2

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Түбән Якый торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар итәм:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Түбән Якый авылында 2024 елның 23 нояберендә 10 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2.Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Түбән Якый торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын уздыру вакыты – 23 нояберендә 2024 ел 10.00 сәг.тән 11.00 сәг.кадәр;
- гражданнар җыенын уздыру урыны – Түбән Якый авылы, Кашапов ур. , 7 нче йорт адресы буенча урнашкан “Якый” кибете каршысында.

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2024 елның 19 ноябереннән дә соңга калмыйча гражданнарга Мәлбагыш авылы, Нефтяниклар урамы, 30 нчы йорт адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитетында , Мәлбагыш авыл Җәлил урамы 1 йорт һәм Түбән Якый авылы, Кашапов урамы, 23 нчы йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын бирергә;
- Түбән Якый торак пунктында сайлау хокукына ия булган яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Түбән Якый торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, махсус хәрби операциягә китүчеләрнең гаилә агъзаларыннан, РФ Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтү өчен контракт төзегән гаилә әгъзаларыннан тыш, Мәлбагыш авыл җирлеге Түбән Якый торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар,яктырткычлар,электр товарлары һәм махсуз җиһазлар сатып алу, алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

- Түбән Якый торак пункты территориясен төзекләндерү (үләннәрне чаптыру,территорияне чистарту һәм чүп-чар җыю хезмәтләре күрсәтү; тракторчыга механикалаштырылган кар чистарту буенча хезмәтләр өчен түләү);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау, тоту ( яңа материал өстәп юлларны профильләү, 8 Март урамындагы юлларга асфальт салу)

« РИЗА» «КАРШЫ».

5. Әлеге карарны Мәлбагыш авылы, Нефтяниклар урамы, 30 нчы йорт адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитетында һәм Түбән Якый авылы, Кашапов урамы, 23 нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. урнаштырырга

6. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык А.Й.Әхмәтшин